ГЛАВА СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 2 — 29 гыйнвар 2016 ел

## 2016 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясе дәүләтнең наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында» 2010 елның 09 июнендәге 690 номерлы Указына таянып, наркомания таралу куркынычын минимальләштерү максатларында һәм Мамадыш районы прокуратурасының 2015 елның 25 июнендәге 02-01-19-2015 номерлы тәкъдиме нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы комиссия төзергә. (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты карамагында наркотикларга каршы комиссия турындагы нигезләмәне расларга . (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә наркотикларга каршы чаралар планын расларга. (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ mamamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең «Норматив хокукый актлар» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Урта Кирмән авыл җирлеге
башлыгы — Б.Ф.Хәсәнов